ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.12.2023 г. Казань № 397-11/т-2023

2024 елга «Тимер юл идарәсе» ҖЧҖ Чаллы шәһәрендәге бүлекчәсе тарафыннан килә торган тимер юлларда күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә максималь дәрәҗәдә чик тарифлар билгеләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 06.12.2023 №52-ПР утырышы беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасына ярашлы рәвештә «Тимер юл идарәсе» ҖЧҖ Чаллы шәһәрендәге бүлекчәсе тарафыннан килә торган тимер юлларда күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә максималь дәрәҗәдә чик тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән максималь дәрәҗәдә чик тарифлар 2024 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С. Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
06.12.2023 № 397-11/т-2023
карарына кушымта

«Тимер юл идарәсе» ҖЧҖ Чаллы шәһәрендәге бүлекчәсе тарафыннан килә торган тимер юлларда күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә максималь дәрәҗәдә чик тарифлар

I бүлек. Чик дәрәҗәдә максималь тариф

| Т/с | Хезмәт төре | Үлчәү берәмлеге | Чик дәрәҗәдә максималь тариф, сумнарда (өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча) |
|---|---|---|---|
| 1. | Чаллы маневр районы буенча 1 км ераклык өчен йөк ташу | 1 тонна | 27,77 |
| 2. | Круглое Поле маневр районы буенча 1 км ераклык өчен йөк ташу | 1 тонна | 19,14 |
| 3. | Сидоровка маневр районы буенча 1 км ераклыкка йөк ташу | 1 тонна | 10,36 |

II бүлек. Башка шартлар

1. Сәнәгать тимер юл транспорты предприятиесе тарафыннан башкарыла торган, әмма «Чик дәрәҗәдә максималь тариф» дигән I бүлектә каралмаган эшләргә һәм хезмәтләр күрсәтүгә тарифлар яклар килешүендә, Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 2001 елның 20 декабрендәге АН-104-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган Сәнәгать тимер юл транспортында башкарыла торган эшләргә һәм хезмәтләр күрсәтүгә тарифлар һәм җыемнар формалаштыру буенча методик күрсәтмәләр нигезендә билгеләнә.

2. Йөк ташу һәм төяп җибәрү-бушату эшләре өчен түләү заказчыдан ташылган йөкнең фактик авырлыгы өчен алына.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге